ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2020 г.Лениногорск №249

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 32 статьяда түбәндәге эчтәлектәге 10нчы часть белән тулыландырырга:

«10. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә мәҗбүри кушымта булып территориаль зоналар чикләренең урнашу урынының график тасвирламасы, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында бу чикләрнең характерлы нокталарының координаталары исемлеге булырга тиеш булган территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр тора.

Җирлекнең җирле үзидарә органы шулай ук территориаль зоналар чикләренең урнашу урынының текст тасвирламасын әзерләргә хокуклы.

Территориаль зоналар чикләрен график һәм текст тасвирламасының формалары, территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталарының координаталарын билгеләү төгәллегенә карата таләпләр, күрсәтелгән белешмәләр булган электрон документ форматына карата таләпләр Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2018 елның 4 маендагы 236 номерлы боерыгы белән билгеләнгән»;

2. Әлеге карарны рәсми публикатор, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов